КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 май г.Казань № 417

Халык саны 100 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларын күчмә медицина комплекслары белән җиһазландыру чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2019 – 2021 елларга халык саны 100 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларын күчмә медицина комплекслары белән җиһазландыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына башка бюджетара трансфертлардан бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1734 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Халык саны 100 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларын күчмә медицина комплекслары белән җиһазландыру чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен расларга.

2. Бу карарның гамәле 2019 елның 12 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 21 май, 417 нче
карары белән расланды

# Халык саны 100 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен медицина оешмаларын күчмә медицина комплекслары белән җиһазландыру чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибе

1. Бу Тәртип халык саны 100 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүчеләргә медицина ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы дәүләт медицина оешмаларын күчмә медицина комплекслары белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу (шул исәптән тулы күләмдә) максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар рәвешендә бирелә торган акчадан (алга таба – акча) файдалану механизмын билгели.

2. Акча, күчмә медицина комплексларының технологик тасвирнамәләре эквивалент булганда, өстенлекне үз илебез җитештерүчеләренең күчмә медицина комплексларына бирү тәкъдимен исәпкә алып бирелә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы була.

4. Акча тоту Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

5. Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәре ирештерелгәннән соң, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре, расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

6. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алулар, эш башкарулар, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә Россия Федерациясенең контракт системасы турындагы законнарына таянып, бу Тәртипнең 2 нче пункты нигезендә күчмә медицина комплекслары сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

күчмә медицина комплекслары сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзегән оешмаларга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартлары нигезендә акча күчерә.

7. Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәгеләрне иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең «Электрон бюджет» дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында урнаштыра:

финанс белән тәэмин итү максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны – хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, ай саен;

башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турындагы хисапны – хисап аеннан соң килә торган айның 10 ысыннан да соңга калмыйча, ай саен.

8. Акчаны максатчан февраль айдаланмау Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җавап бирүгә тарта.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына акчаның файдаланылмый калган өлеше федераль бюджетка Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.